**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 5 июнендәге 1917 номерлы карары**

**2026 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 25 февралендәге 541 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль бирем үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы, 2025 елның 12 мартындагы 660 номерлы «“Шәһәр трансформациясе үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. 2026 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән норматив чыгымнар муниципаль бирем буенча тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру өчен кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, шулай ук аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 5 июнендәге
1917 номерлы карарына
кушымта

**2026 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар**

| № т/б | Муниципаль эш (хезмәт) исеме | Муниципаль эш (хезмәт) эчтәлеге | Эшне (хезмәтне) башкаруга чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасының мәгълүмат системаларын һәм компонентларын булдыру һәм үстерү | Мәгълүматларны эшкәртү үзәге | 28 620,07 |
| 2 | Оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү | Проектлар белән идарә итү | 10 319,93 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | 38 940,0 |